
Газета МБОУ «АСОШ №2»

# Пульс школы

# Мәктәп пульсы



№3
Ноябрь, 2024 г.

## С днём народного единства!




4 ноября в России отмечается День народного единства. Это праздник, объединяющий народы большой страны и напоминающий о важных событиях истории. Пусть мы все разные, но вместе мы — сила! И чем нас больше, тем мы сильнее. Давайте будем жить одной большой семьей, но при этом не терять самобытности, уважать традиции каждого народа. Пусть нас всех объединяют истинные ценности — любовь, дружба, честь. И пусть в жизни каждого будет как можно больше теплых встреч! С Днем народного единства!

4 ноябрьдә Россиядә Халыклар бердәмлеге көне билгеләп үтелә. Бу зур ил халыкларын берләштерүче һәм тарихның мөһим вакыйгаларын хәтерләтүче бәйрәм. Без барыбыз да төрле булсын, әмма без бергә - көч! Без никадәр күбрәк булса, шулкадәр көчлерәк. Әйдәгез, бер зур гаилә белән яшик, әмма шул ук вакытта һәр халыкның гореф-гадәтләрен югалтмыйк. Барыбызны да чын кыйммәтләр - мәхәббәт, дуслык, намус берләштерсен. Һәм һәркем тормышында мөмкин кадәр җылы очрашулар булсын! Халык бердәмлеге көне белән!

**В этом выпуске:**


| | |
|---|---|
| Күрешү мизгеле | 2 |
| Алия мизгелләре... | 3 |
| Из школьной жизни... | 4 |
| Халкымның милли бәйрәме | 5 |

# Көрешү мизгеле

Хыялдагы беренче күрешү ләззәтеннән Айзат тәмам изрәп китте. Менә кайнар сулыш якыная, якыная бара, менә ул битне пешерә башлады, аһ, иреннәр кушылды, сизелер-сизелмәс дерелдәгән иреннәр назга сусап бер-берләренә тартылдылар! Нинди татлы ләззәт, битләр, тәннәр кызыша, йөрәкләр: ‘‘Миңа рәхәт, миңа рәхәт!"— дия-дия, куанышып сикерешәләр, баш әйләнә-ә-ә. Күзләр йомылган, колакта талгын көй. Бу дөньяда без икәү дә сихри көй генә кебек. Чү, көй нигә бетте? Аһ, бу мәктәпмени? Чыннан да, менә классташлар, әнә бер почмакта укытучы дәрес аңлата, арттагы партада Алмаз белән Гаяз шыпырт кына сүз куерта. Эх, нинди сихри халәтне өзделәр, нинди матур мизгелне тук-таттылар!.. Гәүдәләр теләмичә генә бер-берсеннән аерылып, йөгерек көйгә селкенүче төркемгә кушыла. Ә күңелләрдә, йөрәкләрдә бер генә теләк: тагын бер башларны әйләндерәсе, әле генә булган халәтне кичерәсе иде!

Иртәгә мәктәптә кичә була. Ә нигә Алия белән кичәдән бергә китмәскә? Классташларның кайберләре җитәкләшеп кайтып китүебезгә гаҗәпләнсәләр дә, күбесе моңа игътибар итмәячәк. Чөнки икебезнең дә күптән инде яшерен сөю утында янганыбызны беләләр. “Ата казыгыз йомырка саламы?” дигәндәй, юк-бар сүз сөйләшеп, тәнәфес саен аның тирәсендә йөргәнне дә күрәләр. Ә менә аның капка төбенә якын да килгән юк Айзатның. Кыюлыгы җитмиме шунда. Дөрес берничә мәртәбә талпынып карады ул. Тик шунда якынлашуга, әйтәсе килгән барлы-юклы сүзләр дә, кыюлык та бетеп китә. Ә бит әйтәсе килгән уйлар, теләкләр, матур сүзләр бик күп, көне-төне сөйләсәң дә, сөйләп бетереп булмас кебек. Хәер, нигә ми кайнатып, сүз эзләп маташырга, иң мөһиме — бергә, янәшә кайнар сулышны тоеп атлау да җитә. Ничек тә тәвәкәлләргә кирәк. Егет кеше ике уйларга тиеш түгел. Иртәгә ай, йолдызлар, яфракларның аларга: “Бу мәхәббәт! Бу — мәхәббәт!” — дип пышылдауларын уйлап, бу татлы ләззәттән кебек татлы хыялларының тормышка ашуына сөенеп, бер-берсенең кочагында эреп бетәбез дигәндә, сабырсыз партадашы янтыгына төртте:

- Ишетмисеңме әллә, Сания Әшрәповна синә сорау бирде, тор!

Аһ, бу һаман мәктәпмени? Хушлашырга ва-кыт, димәк. Тыныч йокы теләшеп һәм кабат очрашу урынын ачыклап, аерылышасы бар бит әле. Их, Сания Әшрәповна, иң кирәкле урынында татлы хыялларны нигә бозарга иде инде. Бүген дәрестәге игътибарсызлыгы өчен кисәтү алса да, Айзатның күңеле шат иде. Иңнәренә канат куелгандай очып кайтып, өенә керде. Йөрәкләр җилкенә, өйдәгеләрнең берәрсе берәр сүз әйтә күрмәсен дигән теләк, тизрәк хыял дөнгезенә чумарга өндәп, үз бүлмәсенә сөйри. Класстан-класска күтәрелгән саен яшерен генә сөеп, күпме йөргәннән соң, ниһаять, күрешергә дигән ниятен тормышка ашыру теләге артканнан артты егетнең. Нинди булыр икән ул аулакта беренче күрешү! Классташлар үртәрләр инде, өйдәге балачагалар “Фәлән+Фәлән =100 % мәхәббәт”, — дип язып тутырырлар. Әй, язсыннар ла, башлары яшь әле, минем кебек булгач, үзләре дә гыйшык утында үрле-кырлы сикерерләр. Эх, тизрәк мәктәпкә барасы иде дә, Аны күрәсе иде. Моннан соң мәктәпкә тагын да матурланыбрак йөрисе, дәресләргә яхшырак әзерләнәсе була инде — “2”ле алсаң, “чыбыксыз телефон” хәзер илтеп тапшырыр Үзенә, оятыңнан качар җир тапмассың, тьфү-тьфү. Өйдәгеләр сине шайтан куа, бисмилласын укый дип уйлый инде, әй, белсәләр икән алар бүген минем нинди шатлык кичергәнемне, тантана иткәнемне! Нәрсә әйтерләр иде икән? Куркып калырлар иде, мөгаен. Көнозын уем иртәгә мәктәптә буласы кичәдә, аннан соңгы очрашуда булды. Шул очрашу бәхетеннән көлемсерәп, мендәремне Ул дип кысып кочаклап, назлы сүзләр әйтә-әйтә йокыга талам һәм кабат күз алдыма Аны китерәм.

***Руслан** Комаров, 11 сыйныф укучысы.*

# Алия мизгелләре...

Ул көнне Рифат дәресләр бетүгә тизрәк өенә ашыкты. Шуңа күрә укытучы биргән өй эшен дә яхшылап тыңлап тормады. Сәбәбе: аңа беренче сыйныфта укучы сеңлесеннән алдарак кайтып, компьютерга утырырга кирәк иде. Алайса тагын сеңлесенә кибеттән тәм-том алып бирәсе була. Шунсыз бирмәячәк ул компьютерны абыйсына.

Рифат тәки беренче кайтып, ашап та тормыйча, компьютер артына ашыкты. Шунда утыры-утыра, ул татар теленнән бирелгән өй эше турында да онытты. Электрон көндәлекне ачып карарга да уйламады. Иртәгә баргач, берәрсеннән сорап эшләрмен дип, үз-үзен юатты. Шулай итеп, “Сабантуй” темасына ясалган рәсем буенча инша язылмый калды.


Икенче көнне, Рифат өй эшен кемнән күчерәсен юлда ук уйлап барды. Мөгаен, Рәмистән күчерер. Ул бик яхшы укучы түгел үзе. Әнисе булышканда, шәп яза. Ә менә Рифатның әнисе алай вакланып торырга яратмый шул. Өй эшләрен эшләгәнме икәнен дә тикшергәне юк.

Укытучы дәрес башлануга башкаларның дәфтәрләрен җыеп алырга булды. Ә менә Рәмис белән Рифатка такта янына чыгып укып күрсәтергә кушты. Кирәк бит ә, класста укучылар беткәнме алардан башка. Рәсемдәге балаларга класстагы дусларының исемнәре куеп язылган иншасын Рәмис бирде аңа бирүен. Рифатның аны укып чыгарга гына вакыты калмады, тотты да башка исемнәр белән алыштырып күчерде дә куйды. Гүзәл урынына Алия, Ирек урынына Марат дип язды. Алар да безнең сыйныфныкылар бит, шәп булды әле бу дип канәгатьләнеп тә куйды.

Такта янына чыккач, менә шул исемнәр харап итте дә Рифатны. Икенче җөмләне укыганда, бөтен кеше тәгәрәп көлде. “Алия мизгелләре сурәтләнгән”, - дип укыды да туктап калды ул. Бер агарды, бер кызарды. Классны тынычландыргач, укытучы дәвам итәргә кушты. “ Маратка сусаган балаларга көне буе теләгәнчә уйнар чак бу.”, - дип дәвам итте ул. Класс тагын дәррәү шаркылдарга тотынды. Рифатка алга таба укырга кушмады укытучы, урынына утыртты. Рәмисне чакырды. “Рәсемдә сабантуй көне. Гүзәл мизгелләр сурәтләнгән. Ирекkә сусаган балаларга көне буе теләгәнчә уйнар чак бу.”, - дип укып китте ул. Сания апалары инша укылып беткәч: “Хәзер бар да аңлашылды. Күчерткән өчен Рәмискә 2ле,
Рифатның иншасын ата-аналар җыелышында укырга алып калам. Өйдә икегез дә яңадан язып килерсез,” – диде.

Истә мәңгегә калырлык булды бу көн. Күчергәнче, Рифат яхшылап укып чыккан булса, гүзәл матурның, ирек азат сүзенең синонимы икәнен аңлаган һәм көлкегә калмаган булыр иде. Ул бит аны классташларының исемнәре дип белеп алыштырды да куйды. Ашыккан ашка пешкән менә шул буладыр инде ул.

Бу хәлдән соң Рифат компьютердан бизде. Шул сәбәпче булды бит әлеге хәлләргә. Башкача беркайчан да кешедән күчермәскә дип тә сүз бирде әле ул үзенә. Сүзендә торырмы, анысын вакыт күрсәтер.




***Гүзәлия** Фәттахова, 11 сыйныф укучысы.*

# Из школьной жизни...

8 ноября отмечается День памяти погибших при выполнении служебных обязанностей сотрудников органов внутренних дел Российской Федерации, установленный в соответствии с приказом Министерства внутренних дел Российской Федерации. Это день, когда мы чествуем, кто стоит на страже правопорядка, защищает нашу жизнь и безопасность . Однако этот праздник также является напоминаем о том, сколько людей отдали свои жизни ради ради нашей безопасности.

Советник директора по воспитанию и взаимодействию с детскими общественными объединениями Аскарова А. И. провела в 9 «А» классе мероприятие, приуроченный к этой скорбной дате «Имена, которые нельзя забывать» .

В течении урока ребята послушали информацию о роли структуры органов внутренних дел, о службе сотрудников данной структуры, им было рассказано о таких сотрудников, героях России, чьи жизни оборвались на службе Родине, Магомеде Нурбагандове и Ольге Качуре. Эти люди проявили мужество и героизм, защищая нас от преступных посягательств. Их подвиг навсегда останется в наших сердцах. Ребятам был показан видеоролик «Герои нашего времени».



9 ноября коллектив школы, ученики присоединились к всемирной акции «Татарский диктант». Основная цель акции - привлечь внимание к татарскому языку и культуре, дать возможность изучать его, расширить круг потребителей литературного татарского языка и пробудить любовь к татарскому языку.

В этом году акция «Татарский диктант» проводится в девятый раз. Акция сегодня является одним из проектов, который объединяет наших соотечественников, проживающих в Республике Татарстан, Российской Федерации и за рубежом.



11 ноября в нашей школе состоялась торжественная церемония посвящения обучающихся 1-ых в ряды «Орлята России», которые являются первой ступенью Российского движения детей и молодёжи «Движение первых»

С напутственными словами к ребятам обратилась Директор Арской СОШ 2 - Гиниатуллина Г.Г., которая отметила значимость данного события. Ведь быть «Орлёнком» - это не только честь, но и ответственность, это значит во всём и всегда быть впереди, воспитывать в себе любовь к Родине, трудолюбие и стремление к знаниям, честность и благородство, скромность, дисциплинированность и товарищество.



14 ноября в нашей школе состоялось знаменательное, историческое событие. В рамках Всероссийской патриотической акции «Вахта героев» нас посетил Николай Николаевич Ярцев — советский, российский военный лётчик, полковник, Герой России.

Ученики нашей школы, отряд Юнармейцев и коллектив барабанщиц «Ритм» тепло встретили почётного гостя. Николай Николаевич ознакомился с методами патриотического воспитания обучающихся в нашей школы, с музеем и уголком Юнармейцев. Украшением мероприятия стал творческий концерт с участием учащихся и беседа учеников 9-11 классов с Героем. Николай Ярцев рассказал ребятам о своей службе, получении награды «Герой России», о том, как важно быть защитником своей Родины, патриотом.

Выражаем большую благодарность Николаю Николаевичу Ярцеву за посещение нашей школы, района и Республики. Эта встреча стала важной частичкой истории нашей школы.





В рамках мероприятий, посвященных Всемирному дню памяти жертв дорожно-транспортных происшествий была проведена игра - викторина «Своя игра по ПДД». В этом мероприятии приняли участие 6А класс.

Ребятам было предложено несколько заданий, с которыми они справились на отлично.






В 8А классе прошел классный час на тему «Современный этикет». Целью этого мероприятия было усвоение основных этических требований в поведении и общении с людьми, овладение навыками культурного поведения.

Ефимова.К и Минзиева Э. рассказали о правилах этикета и ознакомили с устным журналом..



# Халкымның милли бәйрәме

Татар халкында язгы эшләр белән бәйле бәйрәмнәрнең иң күңеллесе ул - Сабантуй. Бу бәйрәм язгы сабан белән бәйләнгән. Сабантуй бәйрәме элек-электән барлыкка килгән бәйрәмнәрнең берсе.

Тарихчылар язганча, Казан ханлыгы чорында Сабантуй мәйданында хәтта шәригать кануннары да йомшарып торган. Ир-атлар белән беррәттән хатын-кызлар да барлык уеннарда да диярлек катнаша алган. Аның уеннары да җиңел булган. Бердән, алар бик гади, һәркемгә аңлаешлы. Икенчедән, олысы-кечесе ярыша алырлык итеп оештырылган. Бердәнбер искәрмә - көрәш, анысы аерым әзерлек, аерым осталык таләп итә. Тик анда да бәйге балалар көрәшеннән башлана. Мәйдан түгәрәк, бөтен кеше дә сыярлык, барлык тантана һәркемгә күренерлек итеп эшләнгән.

Сабантуйлар төрле җирдә төрлечә уза.Сабантуй башланырга биш-алты көн кала авылның яшь егетләре җыелып яулык җыярга чыгалар, аларга кызыгып кечерәкләр дә кушыла. Яулык җыючы егетләр авылның бер башыннан килеп гармунга кушылып җырлыйлар, бииләр һәм өйләргә кереп бүләк җыялар. Гармун авазы, яшләр җыры бар авылга тарала. Авыл халкы алдан ук бүләкләрен әзерләп куя. Бүләк итеп яулык, ситса, сөлге кебек әйберләр бирелә. Кайбер яшь, көрәшче егетләр ныгыр өчен йомырка эчәләр. Яшьләр һәр бүләккә рәхмәт әйтәләр. Кайбер кешеләр бүләк биргәнче яшьләрне гармун көенә биетәләр. Шулай итеп бар кешедән дә бүләкләр җыйгач, Сабантуй мәйданына төшеп урнаштыралар һәм өйгә таралышалар. Көтеп алган Сабантуй бәйрәме дә килеп җитә. Авылга шәһәрдән кунаклар, яшьләр кайталар. Бар авыл халкы Сабантуй бәйрәменә әзерләнә. Сабантуй һәрвакыттагыча кечкенә балалар көрәшеннән башлана. Уенда катнашучыларга барсына да бүләкләр тапшырыла. Мәйданга халык җыела тора. Балалар көрәше тәмамланганнан соң, яшьләр көрәше башлана. Бу вакытта балалар капчык белән сугыша, кыек һәм туры баганага менә. Мәйданга җыелган халыкның берсе дә уеннарда катнашып бүләк алмыйча калмыйдыр. Өлкәнерәкләр катыкка керсә, чүлмәк ватса, яшьләр уклау тарта, кул көрәштерә, гер күтәрә. Мәйдан уртасында уеннар һич кенә дә тынып тормый. Кемнәрдер аркан тартыша, кемнәрдер бии, җырлый.

Әлеге бәйрәмнең тамырлары бик борынгы чорга тоташа – аны мәҗүсилек чорында ук ерак ата-бабаларыбыз билгеләп үткән. Ул чорда аны кар эреп бетү белән сабанга төшкәнче үткәргәннәр. Галимнәр Әлки районында 1120 елга караган кабер ташы да тапканнар, анда мәрхүмәнең Сабантуй көнне вафат булуы язылган икән. Революциядән соң бәйрәмгә яңа тәртипләр кертелә - ул чәчүдән соң уздырыла башлый. Совет чорында да Сабантуй үзенең үзенчәлеген саклый, ул һәр авылда борынгы гадәтләр буенча үткәрелеп килә. Минемчә, соңгы елларда бәйрәм үзенең гореф-гадәтләрен югалта башлаган кебек. Хәер, бу минем фикерем. Дуслар, сезнең фикерне дә беләсе килә.

***Әмир** Гыйлфанов, 9А сыйныф укучысы.*


***Редактор*** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.

***Дизайнер - верстальщик*** Гузелия Фаттахова

***Фотокорреспондент*** Илюза Шамсемухаметова

***Корректор*** Гузелия Фаттахова

***Редколлегия*** Камилла Мифтахова

***Адрес:*** ул. Мостовая, дом 15

***Сайт школы:*** https://edu.tatar.ru/arsk/sch2